| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ТАШКИЧИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,<br>Арский муниципальный район, 422039 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАШКИЧҮ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422039 |

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

Ташкичү авыл җирлеге Советы

КАРАР

21.05.2024 ел № 5

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына Ташкичү авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Арча район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Ташкичү авыл җирлеге башкарма комитетына:

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә Ташкичү авыл җирлеге Советының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар

план чорына Ташкичү авыл җирлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләргә һәм карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Хәбибуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ОГРН 1121690000052 * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ТАШКИЧИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
СОВЕТ ТАШКИЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012580